КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 13 гыйнвар г.Казань № 4

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» 2016 ел, 13 август, 553 нче карары белән расланган Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» 2016 ел, 13 август, 553 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 10 октябрь, 732 нче; 2017 ел, 18 сентябрь, 675 нче; 2019 ел, 17 июнь, 498 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибенә,

2.1 пунктның өченче абзацында татар текстында «стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруны күздә тоткан җир кишәрлеген арендалау шартнамәсенең гамәлдә булу» сүзләреннән соң «яки яклар килешүе буенча аны өзү» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин